| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ОЛУЯЗСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ<br>422127, РТ, Кукморский район, с.Олуяз, ул. Новая, д. 11<br>Эл.почта: Olu.Kuk@tatar.ru<br>тел./факс: 8 (84364) 39-5-83 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫЯЗ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>422127, РТ, Кукмара районы, Олыяз авылы, Яңа урам, йорт 11<br>Эл.почта: Olu.Kuk@tatar.ru<br>тел./факс: 8 (84364) 39-5-83 |
| --- | --- |

КАРАР

30 октябрь 2023 ел № 32

Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Олыяз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Олыяз авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2018 елның 07 ноябрендәге 29 номерлы, 2019 елның 15 маендагы 7 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 6 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 6 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

б) 7 нче бүлектә:

5 нче пунктны «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

7 нче пунктны «федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

10 нчы бүлектә:

7 нче пунктта «дөрес булмаган яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге 7.1 пункты белән тулыландырырга:

«7.1. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

10 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алыштырырга;

б) 24 нче бүлектә:

түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга:

«1.1. Мунципаль хезмәткәр, «Муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү ажардан бәйсез булган хәлләр тикшерүе тарафыннан «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылa икән ришвәтчелеккә каршы тору максатында җаваплылыктан азат ителә.»;

3 пунктның 1 пунктчасын «яки «Ришвәтчелеккә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан» дигән сүзләр белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы Р. Ф. Маликов